ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья. Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек башкаручы субъектлар, әлеге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керүче оешмалар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

**2 статья. Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте өлкәсендә хокукый җайга салу**

1. Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте өлкәсендә хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга нигезләнә һәм "Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында" 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, "Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында" 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында" 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.
2. Әлеге Закон составында спирт булган азык-төлек продукциясе, алкоголь продукциясе һәм тәмәке әйберләре җитештерүгә бәйле мөнәсәбәтләргә карата кулланылмый.

**3 статья. Төп терминнар һәм төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте (алга таба шулай ук – сәнәгать сәясәте) – Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте максатларын, бурычларын һәм принципларын исәпкә алып, Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәтен формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу кысаларында Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү максатларында Татарстан Республикасының сәнәгать потенциалын үстерүгә, конкурентлыкка сәләтле сыйфатлы продукция җитештерүне тәэмин итүгә, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга, сәнәгатьне нисбәтле һәм тотрыклы үстерүгә юнәлдерелгән хокукый, икътисадый, социаль, оештыру, мәгълүмати, белем бирү һәм башка чаралар комплексы;

2) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары – Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар;

3) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чаралары – Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керә торган оешмалар тарафыннан башкарыла торган һәм сәнәгать сәясәте максатларына ирешүгә юнәлдерелгән хокукый, икътисадый һәм оештыру характерындагы гамәлләр;

4) импорт алмаштыру – аерым товарлар импортын Россия җитештерүчеләре тарафыннан шундый ук товарлар яисә аларның конкурентлыкка сәләтле аналогын чыгару юлы белән киметү яисә туктату;

5) индустриаль (сәнәгать) парк – сәнәгать җитештерүен яисә сәнәгать җитештерүен модернизацияләүне булдыру өчен билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән идарәче компания – коммерцияле яисә коммерциягә карамаган оешма тарафыннан идарә ителә торган сәнәгать инфраструктурасы объектлары җыелмасы;

6) сәнәгать кластеры – территориаль якынлык һәм функциональ бәйлелек нигезендә сәнәгать өлкәсендәге мөнәсәбәтләргә бәйле һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күрсәтелгән өлкәдәге эшчәнлек субъектлары җыелмасы;

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка терминнар һәм төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

4 статья. **Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтенең максатлары һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтенең система барлыкка китерү максатлары продукциянең конкурентлыкка сәләтен һәм сәнәгатьнең техник дәрәҗәсен арттырудан, инновацион продукцияне һәм югары технологияләрне эчке һәм тышкы базарларга чыгаруны тәэмин итүдән, импорт продукциясен алмаштырудан һәм сәнәгатьне инновацион актив сәнәгать җитештерүе нигезендә тотрыклы үсеш баскычына күчерүдән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасы компетенциясе чикләрендә сәнәгать сәясәте бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) эшкәртү тармаклары продукциясен җитештерүнең чимал табу тармаклары белән чагыштырганда алданрак үсешен тәэмин итү, продукциянең, технологияләрнең, материалларның яңа төрләрен эшләү, булган фәнни-техник потенциалдан һәм фундаменталь, гамәли тикшеренүләрнең яңа нәтиҗәләреннән файдалану;

2) эчке һәм тышкы базар ихтыяҗын өйрәнү нигезендә җитештерүне оештыру һәм кооперацияне, шул исәптән трансмилли кооперацияне үстерү;

3) Татарстан Республикасының сәнәгать комплексында кластер берәмлекләрен нәтиҗәле формалаштыру һәм үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру, сәнәгать комплексы урнашуның региональ, аерым алганда территориаль үзенчәлекләрен истә тоту;

4) сәнәгатьне тотрыклыландыруның һәм икътисадый үстерүнең барлык ресурсларын бәяләү һәм алардан тулысынча файдалану;

5) конкурентлык мохитен үстерү, икътисадый эшчәнлекнең тигез һәм алдан билгеле шартларын тудыру;

6) импортны алмаштыруның формалашып килүче эзлеклелегенә ярдәм итү юлы белән икътисадый үсешне кызыксындыру;

7) Россия базарына һәм халыкара базарларга юнәлеш тоту;

8) экспортка ярдәм итүгә һәм эчке базарның яңа сегментларын үзләштерүгә юнәлдерелгән кредит һәм лизинг институтлары булдыруга ярдәм итү;

9) җитештерү баскычларын һәм аерым технологияләрне модернизацияләү, аларның структурасын үзгәртеп кору;

10) техник регламентларны үтәүгә дәүләт контролен (күзәтчелеген) көчәйтү һәм продукциянең заманча сыйфат системаларын, сертификациясен гамәлгә кертү;

11) икеләтә билгеләнештәге технологияләрне үстерү, моңа яңа материаллар барлыкка китерү технологияләре, мәгълүмат технологияләре, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге технологияләр һәм башка технологияләр керә;

12) өстәлгән бәясе югары булган эшкәртү тармаклары продукциясе өлешен даими арттырып, экспортны диверсификацияләү;

13) фән, мәгариф һәм сәнәгать интеграциясе, фәнни, югары технологияле, ресурсларны сакчыл тотучы, имин һәм экологик чиста производстволарны үстерү.

5 статья. **Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашучылар**

Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашучылар – Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары, әлеге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керүче, шул исәптән сәнәгать өлкәсендә эш бирүчеләрне берләштерүче коммерциягә карамаган оешмалар.

6 статья. **Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) сәнәгать сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итә;

2) сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын кабул итә;

3) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган фәнни техник һәм инновацион программаларны һәм проектларны, шул исәптән Татарстан Республикасы фәнни оешмалары тарафыннан, эшләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыра;

4) федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы белән сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыру турында килешүләр төзи;

5) сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә, шул исәптән сәнәгать өлкәсендә стратегик планлаштыру документлары проектларын эшләү буенча, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарын билгели;

6) федераль законнарда, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән кызыксындыру чараларын индустриаль (сәнәгать) паркларга һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләренә, сәнәгать кластерларына, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларына бирү максатларында аларга карата өстәмә таләпләр билгели;

7) Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларга һәм сәнәгать кластерларына Татарстан Республикасы мөлкәте һәм бюджеты акчалары исәбеннән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын бирү тәртибен раслый, шулай ук бюджет акчаларын максатчан куллануны тикшереп тора;

8) сәнәгатьне үстерүнең дәүләт фондларын төзи;

9) Татарстан Республикасының сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасы сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган акчалар исәбеннән финанс ярдәме күрсәтү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләрен билгели;

10) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында сәнәгать сәясәте өлкәсендә координацион һәм киңәшмә органнары төзү турында карарлар кабул итә, аларның составын һәм алар турындагы нигезләмәләрне раслый;

11) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына ел саен Татарстан Республикасында сәнәгать торышы һәм үсеше турында, Татарстан Республикасында сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашыру хакында доклад тапшыра;

12) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә сәнәгать сәясәте өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Сәнәгать өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы (алга таба – сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган):

1) федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

2) сәнәгать сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының норматив хокукый актларын әзерли;

3) Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать үсешенә ярдәм итә торган чараларны гамәлгә ашыра;

4) сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында кабул ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын әзерли һәм аларны башкаруны тәэмин итә;

5) Татарстан Республикасында сәнәгать торышын мониторинглауны гамәлгә ашыра һәм кирәкле мәгълүмат соратып ала, Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының тотрыксыз үсеше куркынычын кисәтү чараларын күрә;

6) сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне кызыксындыру буенча тәкъдимнәр әзерли, Татарстан Республикасында сәнәгать торышы һәм үсеше турында, Татарстан Республикасында сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашыру хакында еллык доклад әзерли һәм аны бастырып чыгара;

7) Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларны һәм сәнәгать кластерларын төзү һәм үстерү мәсьәләләре буенча сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

8) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы оешмалары белән берлектә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтүдә катнаша;

9) сәнәгать кластерларына, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларына карата әлеге Законда, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән кызыксындыру чараларын куллану максатларында шушы сәнәгать кластерларының, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән өстәмә таләпләргә туры килүен раслый;

10) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасы территориясендә булган хезмәт ресурслары һәм яңа эш урыннарын булдырудагы ихтыяҗлар турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә;

11) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының региональ һәм регионара хезмәттәшлеген үстерүгә, сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары белән башка оешмалар арасында җитештерү һәм сәүдә багланышлары булдыру һәм үстерү юлы белән сәнәгать кооперациясен үстерүгә ярдәм итә;

12) үз вәкаләтләре чикләрендә федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, халыкара оешмалар һәм чит илләрнең административ-территориаль берәмлекләре белән сәнәгать сәясәте өлкәсендә хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

13) үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы территориясендә оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең эшчәнлеге һәм үсеше мәсьәләләре

буенча Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлек итә;

14) федераль башкарма хакимият органнары белән Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыру турында килешүләр әзерли һәм аларга имза салуны тәэмин итә;

15) дәүләт мәгълүмати сәнәгать системасы операторына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән составта һәм тәртиптә мәгълүмат бирүне тәэмин итә;

16) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән үзенә йөкләнгән сәнәгать өлкәсендәге башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

7 статья. **Сәнәгать сәясәте өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнары федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлекләр уставлары нигезендә муниципаль берәмлекләр территорияләрендә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашырырга хокуклы.

8 статья. **Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чаралары**

Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру аның субъектларына түбәндәге дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме;

2) импорт алмаштыруны, сәнәгать кооперациясен үстерүгә ярдәм итү;

3) сәнәгать өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлеккә һәм инновация эшчәнлегенә ярдәм итү;

4) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына аларның кадрлар потенциалын үстерү өлкәсендә ярдәм күрсәтү;

5) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына тышкы икътисадый эшчәнлек өлкәсендә ярдәм итү;

6) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына мәгълүмат-консультация ярдәме күрсәтү;

7) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына аларның Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының дәүләт программаларында катнашу мәсьәләләрендә ярдәм итү;

8) ярдәм итүнең Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка чаралары.

9 статья. **Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме**

Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме Россия Федерациясе законнарында, Федераль законда, шулай ук Татарстан Республикасы

вәкаләтләре кысаларында әлеге Законда, “Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында” 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законында, “Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында” 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган рәвешләрдә сәнәгатьнең аерым тармакларының торышын исәпкә алып күрсәтелә.

10 статья. **Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары**

1. Татарстан Республикасы тарафыннан фонд яисә автоном учреждение оештыру-хокукый рәвешендә төзелгән дә, төзелә торган да, йә Татарстан Республикасының сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керә торган оешмалар белән берлектә фонд оештыру-хокукый рәвешендә төзелә торган Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтәләр.

2. Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары Татарстан Республикасының сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керә торган оешмалар була. Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондын гамәлгә куючының вәкаләтләрен һәм функцияләрен Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты башкара, ул гамәлгә куючы вәкаләтләренең һәм функцияләренең өлешен сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле органга тапшырырга хокуклы.

3. Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары мөстәкыйль рәвештә яисә Татарстан Республикасының сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керә торган оешмалар белән берлектә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Россия Федерациясе законнарына туры килә торган теләсә кайсы рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән финанс ярдәме күрсәтәләр.

4. Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары финанс ярдәме белән беррәттән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына ярдәм итүнең Федераль законда һәм әлеге Законда каралган башка төрләрен күрсәтергә хокуклы.

11 статья. **Татарстан Республикасы исеменнән махсус инвестиция контракты**

1. Татарстан Республикасы исеменнән махсус инвестиция контракты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан төзелә.

2. Әгәр башкасы Федераль законда каралмаган булса һәм махсус инвестиция контрактының асылына каршы килмәсә, махсус инвестиция контрактына карата

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының инвестиция эшчәнлеге турындагы законнарының нигезләмәләре кулланыла.

3. Махсус инвестиция контрактының ягы булган инвесторга һәм (яисә) махсус инвестиция контрактында күрсәтелгән башка затларга карата муниципаль хокукый актларда каралган сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашыру максатларында махсус инвестиция контрактының яклары Татарстан Республикасы белән бергәттән муниципаль берәмлекләр булырга мөмкин.

4. Махсус инвестиция контрактын Татарстан Республикасы тарафыннан төзү тәртибе, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән махсус инвестиция контракты төзү тәртибен һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган типлаштырылган рәвешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

12 статья. **Индустриаль (сәнәгать) парклар**

1. Индустриаль (сәнәгать) парклар, индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләре аларга карата сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллану максатларында индустриаль (сәнәгать) паркка һәм индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән төп таләпләргә җавап бирергә тиеш.

2. Индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә һәм сәнәгать инфраструктурасы объектларыннан файдаланучы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына карата сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллану максатларында индустриаль (сәнәгать) паркка һәм индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә карата өстәмә таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

3. Индустриаль (сәнәгать) паркның һәм индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенең индустриаль (сәнәгать) паркка, индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә карата Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендәге вәкаләтле органы әлеге статьяда билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаган индустриаль (сәнәгать) паркларның, индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләренең реестрын алып бара һәм сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына әлеге реестрдан өземтәләр бирә. Күрсәтелгән реестрны алып бару тәртибен әлеге вәкаләтле орган билгели.

13 статья. **Сәнәгать кластерлары**

1. Сәнәгать кластерларына карата әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллану, сәнәгать кластерын үстерүне методик, оештыру, эксперт-аналитик һәм мәгълүмати тәэмин итүне

гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешма төзү һәм сәнәгать кластерының, сәнәгать кластерының махсуслаштырылган оешмасының Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән өстәмә таләпләргә туры килүе шарты белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Сәнәгать кластерының һәм сәнәгать кластерының махсуслаштырылган оешмасының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән өстәмә таләпләргә туры килүен раслауны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.

3. Сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаган сәнәгать кластерларының һәм сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларының реестрын алып баруны гамәлгә ашыра. Күрсәтелгән реестрны алып бару тәртибен әлеге вәкаләтле орган билгели.

14 статья. **Дәүләт мәгълүмати сәнәгать системасы белән хезмәттәшлек**

1. Сәнәгать сәясәтен формалаштыруда катнашучыларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү, алар арасындагы нәтиҗәле хезмәттәшлекне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән составта һәм тәртиптә дәүләт мәгълүмати сәнәгать системасы операторына мәгълүмат бирүне тәэмин итә.

2. Үзләренә карата әлеге Законда каралган сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне кызыксындыру чаралары кулланылган йә шушы чараларны куллануга дәгъва итүче сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле органга дәүләт мәгълүмати сәнәгать системасына кертү өчен кирәкле мәгълүматны, файдалануы федераль законнар белән чикләнгән мәгълүматтан тыш, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырырга тиеш.

15 статья. **Сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашырганда фәнни-техник эшчәнлеккә һәм инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү**

Сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашырганда фәнни-техник эшчәнлеккә һәм инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына дәүләт оборонасын һәм иминлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган сәнәгать тармакларында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру барышында башкарыла торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технология эшләрен финанслауга субсидияләр бирү;

2) Татарстан Республикасы катнашындагы хуҗалык җәмгыятьләрендә йә Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмаларда Татарстан Республикасының тиешле хуҗалык җәмгыятендә катнашучы (акционер)

яисә коммерциягә карамаган оешманы гамәлгә куючы буларак хокукларын гамәлгә ашыру юлы белән инновация эшчәнлеген кызыксындыру;

3) инновацион продукциягә ихтыяҗны, шул исәптән дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә нормалар билгеләү аша кызыксындыру;

4) сәнәгать производстволарының экологик иминлек дәрәҗәсен, шул исәптән иң яхшы технологияләрдән файдалану ярдәмендә, күтәрү буенча проектларны гамәлгә ашыруда инжиниринг хезмәтләрен күрсәткәндә инновация эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга финанс ярдәме күрсәтү;

5) фәнни, фәнни-техник эшчәнлекне һәм инновация эшчәнлеген башкарганда сәнәгать өлкәсендәге субъектларның эшчәнлеген координацияләү өчен һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрләре субъектлары арасындагы кооперация өчен шартлар тудыру;

6) сәнәгать продукциясен җитештерүне булдыру яисә аны күпләп җитештерү эшчәнлеген фән, техника һәм технологияләрне үстерүнең өстенлекле юнәлешләренә яисә критик технологияләргә карый торган интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен производствога кертү юлы белән кызыксындыру;

7) сәнәгать җитештерүендә файдаланып булган иң яхшы технологияләрне куллану буенча эшчәнлекне кызыксындыру.

16 статья. **Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына кадрлар потенциалын үстерү өлкәсендә ярдәм**

Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына кадрлар потенциалын үстерү өлкәсендә ярдәм түбәндәгечә күрсәтелергә мөмкин:

1) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары хезмәткәрләре өчен өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга мәгълүмат һәм консультация ярдәме күрсәтеп;

2) күрсәтелгән субъектларның хезмәткәрләре өчен өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм теоретик белемнәрнең тәҗрибә күнекмәләре һәм осталыклары белән бергә үрелүен тәэмин итүче оешмаларны төзүдә катнашучы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтеп;

3) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына алар тарафыннан өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеге гамәлгә ашырылганда ярдәм күрсәтүгә бәйле башка чаралар күреп.

17 статья. **Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына тышкы икътисадый эшчәнлек өлкәсендә ярдәм**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына түбәндәгечә ярдәм күрсәтә алалар:

1) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән сәнәгать продукциясен чит ил базарларына чыгаруга Татарстан Республикасы вәкиллекләре институтын җәлеп итү юлы белән булышлык күрсәтеп;

2) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән сәнәгать продукциясе экспортын гамәлгә ашыручы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары өчен Таможня берлегенең таможня законнары һәм таможня эше турында Россия Федерациясе законнары нигезендә уңай шартлар тудырып;

3) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән сәнәгать продукциясе экспортын гамәлгә ашыручы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәмен һәм мөлкәткә кагылышлы булышлык күрсәтеп;

4) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән сәнәгать продукциясе экспортын гамәлгә ашыручы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына ярдәм итүнең башка чараларын башкарып.

18 статья. **Импорт алмаштыру өлкәсендә сәнәгать сәясәте**

1. Сәнәгать өлкәсендә импорт алмаштыруны үстерү үзенең характеристикалары буенча импорттан кертелә торган аналогларына туры килә торган йә үзлекләре һәм сыйфаты буенча алардан яхшырак, конкуренциягә сәләтле сәнәгать продукциясен җитештерүне оештыру һәм арттыру өчен башкарыла торган чаралар комплексын гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

2. Импорт алмаштыруны үстерүгә юнәлдерелгән сәнәгать сәясәте үз эченә түбәндәгеләрне алырга мөмкин:

1) импортны алмаштыра торган продукцияне җитештерүче сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары өчен Татарстан Республикасы законнары нигезендә уңай шартлар тудыру чаралары;

2) импорттан кертелә торган продукциянең конкуренциягә сәләтле аналогларын җитештерүне Татарстан Республикасы территориясендә булдыру һәм үстерү өчен башкарыла торган сәнәгать эшчәнлеген финанс белән кызыксындыру чаралары;

3) Татарстан Республикасына импорттан кертелә торган, Татарстан Республикасында яисә Россия Федерациясе субъектларында җитештерелми торган һәм җитештерелә алмаган һәм сәнәгать продукциясен җитештерү өчен кулланыла торган материалларга, чималга, комплект детальләренә, җиһазларга һәм технологияләргә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының ихтыяҗын турыдан-туры булмаган алмаштыруга яисә киметүгә ярдәм чаралары;

4) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының производство ихтыяҗлары өчен комплект детальләренең бер урында җитештерелүен арттыру чаралары.

3. Сәнәгатьтә импорт алмаштыруны үстерү чараларын гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

19 статья. **Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына мәгълүмат-консультация ярдәме**

Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан мәгълүмат-консультация ярдәме шул исәптән түбәндәгечә күрсәтелергә мөмкин:

1) сәнәгать продукциясен җитештерү өчен кирәкле икътисадый, хокукый, җитештерү-технологик мәгълүматны һәм маркетинг өлкәсендәге мәгълүматны үз эченә алган каталоглар, белешмәлекләр, бюллетеньнәр нәшер итүне һәм (яисә) белешмәләр базаларын, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайтлар алып баруны финанслау аша;

2) күргәзмәләр, ярминкәләр, конференцияләр (шул исәптән халыкара) үткәрүне оештыру яисә аларны үткәрүдә ярдәм итү аша;

3) ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендәге программалар материалларыннан кала башка мәгълүмат-реклама материалларын урнаштыру яисә аларны урнаштыруда ярдәм итү аша.

20 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 21 апреле
№ 24-ТРЗ